**МИНИСТЕРСТВО**
**ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ**
**МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
11.09.2023

**БОЕРЫК**
344
№

г.Казань

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алу өчен түләү кагыйдәләрен раслау турында» 860 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 8 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирүнең Якынча тәртибен раслау турында» 1068 номерлы карары нигезендә, 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керә алуны тәэмин итү турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта буларак бирелгән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирү Тәртибен расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуыны үз өстемә алам.

Министр Р.Н.Садыйков

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
«___»______ 20____№ __
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирү
Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алу өчен түләү кагыйдәләрен раслау турында» 860 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 8 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирүнең Якынча тәртибен раслау турында» 1068 номерлы карары нигезендә, 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керә алуны тәэмин итү турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында эшләнелгән һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) эшчәнлеге турындагы мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында кулланыла торган төп терминнар һәм билгеләмәләр:

1) Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүмат Министрлык яки Министрлык карамагындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә төзелгән яисә Министрлык һәм күрсәтелгән оешмалардан кабул ителгән мәгълүмат (шул исәптән документлаштырылган). Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүматка шулай ук Министрлыкның һәм күрсәтелгән оешмаларның структурасын, вәкаләтләрен, эшчәнлеген формалаштыру һәм тәртибен билгеләүче законнар һәм башка норматив хокукый актлар, аларның эшчәнлегенә кагылышлы башка мәгълүмат (алга таба – мәгълүмат) керә;

2) мәгълүматны файдаланучы - Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүмат эзләүне гамәлгә ашыручы граждан (физик зат), оешма (юридик зат), дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый берләшмә;

3) сорату – файдаланучының, министрлыкка яки аның вазыйфаи затына, телдән яки язма рәвештә, шул исәптән электрон документ рәвешендә Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүмат алу турында мөрәҗәгать итүе;

4) рәсми сайт – Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге сайт.

## 2. Мәгълүматны файдаланучыга аның соратуы буенча бирү Тәртибе

2.1. Министрлыкка язма рәвештә килгән сорату өч көн эчендә теркәлергә тиеш. Телгән бирелгән сорату, кабул ителгән көнне, кабул итү көне һәм вакыты күрсәтелгән килеш теркәлергә тиеш.

2.2. Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, сорату Министрлык тарафыннан теркәлгән көннән алып утыз көн эчендә каралырга тиеш.

Әгәр дә күрсәтелгән көннәр эчендә соралган мәгълүматны бирү мөмкин булмаса, Министрлык кулланучыга сорату теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, соратуга җавапны кичектерү турында, аның сәбәбен һәм соратылган мәгълүматны бирү вакытын күрсәтеп, соратуга җавап бирү өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән унбиш көннән арттырмыйча, хәбәр итә.

2.3. Министрлык, файдаланучыга Министрлык эшчәнлеге турында кирәкле мәгълүматны мәгълүмат белән тәэмин итү максатыннан соратуның эчтәлеген ачыкларга хокуклы.

2.4. Мәгълүмат файдаланучыга соралган мәгълүматны үз эченә алган яки аңа кушымта буларак бирелгән яки әлеге Тәртипнең 2.8 пунктына ярашлы рәвештә күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тартуны үз эченә алган соратуга җавап буларак бирелә.

Соратуга җавапта Министрлыкның атамасы, почта адресы, җавапка кул куйган затның вазифасы, шулай ук соратуга җавап реквизитлары (теркәү номеры һәм көне) күрсәтелә.

Соратуга җавап Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.5. Файдаланучының теләге буенча, мәгълүмат сорала торган мәгълүмат аңа телдән яки документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән почта аша кәгазь документ яки интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә электрон документ рәвешендә, шулай ук гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре буенча бирелә.

Әгәр кулланучы мәгълүматны Министрлыкта кәгазьдә яки компьютер туплау җайланмасында алырга тели икән, Министрлык әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган көннәр эчендә, соратуга җавап итеп, файдаланучыга структур бүлекчә һәм аның вазифаи зат турында структур бүлекчәнең адресы, телефоны, эш көннәре яки

кабул итүнең төгәл көне күрсәтелгән соралган мәгълүматны күрсәтеп, өстәмә мәгълүмат бирә.

Әгәр бу максатларда министрлыкта махсус үткәрү режимы урнаштырылган булса, файдаланучыга җавап итеп аның турындагы мәгълүмат та җиткерелә.

2.6. Мәгълүмат, мондый төр мәгълүмат бирү тәртибен регламентташтыручы законнар нигезендә, түләүсез рәвештә бирелә.

2.7. Министрлык тарафыннан төгәл булмаган мәгълүматлар бирелгән очракта, Министрлык мәгълүмат кулланучының язма гаризасы буенча түләүсез рәвештә, булган төгәлсезлекләрне бетерергә бурычлы.

2.8. Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү мөмкинлеген булдырмауга нигезләр:

1) соратуның эчтәлеге Министрлык эшчәнлеге турында соратылган мәгълүматны билгеләргә мөмкинлек бирмәсә;

2) соратуда почта адресы, электрон почта адресы яки соратуга җавап бирү өчен факс номеры яки сорату җибәргән файдаланучы белән элемтәгә керергә мөмкин булган телефон номеры күрсәтелмәгән булса;

3) соратылган мәгълүмат Министрлык эшчәнлегенә кагылмаса;

4) соратылган мәгълүмат федераль законнар нигезендә чикләнгән керү мәгълүматына караса;

5) соратылган мәгълүмат элек кулланучыга мәгълүмат белән бирелгән булса;

6) соратуда Министрлык кабул иткән актларны хокукый бәяләү, аның эшчәнлеген анализлау яки кулланучының хокукларын яклау белән турыдан-туры бәйле булмаган башка аналитик эш үткәрү турында сорау куелса.

Министрлык, мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан яки рәсми сайтта урнаштырылган булса, сорату буенча үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирмәскә хокуклы. Бу очракта, соратуга җавап итеп, Министрлык соратылган мәгълүматны бастырган массакүләм мәгълүмат чарасының исемен, чыгу көнен һәм номерын һәм (яки) соратылган мәгълүмат урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресын күрсәтү белән чикләнә.

2.9. Әгәр сорату Министрлык эшчәнлегенә кагылмый икән, ул Министрлыкта сорату теркәлгәннән соң җиде көн эчендә, вәкаләтләренә соратылган мәгълүматны бирү кертелгән, дәүләт органына яки җирле үзидарә органына җибәрелә. Шул ук вакытта соратуның адреслашуы турында сорату җибәргән файдаланучыга мәгълүмат белән хәбәр ителә.

Әгәр Министрлыкта башка дәүләт органында яки җирле үзидарә органында соратылган мәгълүматның булуы турында мәгълүмат булмаса, бу хакта шулай ук сорату теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә сорату җибәргән файдаланучыга мәгълүмат белән хәбәр ителә.

2.10. Әгәр соратылган мәгълүмат федераль закон нигезендә чикләнгән керү мәгълүматына карый икән, соратуга җавап итеп, әлеге мәгълүматка керү чикләнгән актның төре, исеме, номеры һәм кабул ителгән көне күрсәтелә. Әгәр соратылган мәгълүматның бер өлеше чикләнгән керү мәгълүматына караса, ә калган мәгълүмат һәркемгә дә ачык икән, министрлык, чикләнгән мәгълүматтан тыш, соратылган мәгълүматны гына бирә.

2.11. Министрлыкка сорату чит телдә килгән очракта, Министрлык аны рус теленә тәрҗемә итүне тәэмин итә. Мондый мөрәҗәгатьне карау әлеге Тәртип буенча башкарыла. Соратуга җавап биргәндә Россия Федерациясенең дәүләт теле кулланыла.